РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
**ГЛАВА**
***Старобарышевского***
***сельского поселения***
Камско-Устьинского
муниципального района

422835, с. Старое Барышево, ул.Центральная, 15
тел.(884377)3-03-18, ИНН / КПП 1622004570 / 162201001 ОКПО 93064659 ОГРН 1061672003436

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
Кама Тамагы
муниципаль районы
***Иске Барыш***
***авыл җирлеге***
**БАШЛЫГЫ**

422835, Иске Барыш авылы, Үзәк урамы, 15
тел.(884377)3-03-18, ИНН / КПП 1622004570 / 162201001
ОКПО 93064659 ОГРН 1061672003436

КАРАР

«12» ноябрь 2020 ел № 12

Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Иске Барыш авыл җирлегенең Иске Барыш торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Иске Барыш авыл җирлеге Уставының 24.1 статьясы нигезендә карар бирәм:

1. 2020 елның 12 ноябрендә 10 сәгать 00 минутка Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Иске Барыш авыл җирлегенең Иске Барыш торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыены билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

“Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Иске Барыш авыл җирлегенең Иске Барыш авылында 2020 елдагы гражданнарның үзара салымын хәл итү өчен 22 100 (егерме ике мең бер йөз) сум күләмендә кабул итү буенча үткәрелгән эш нәтиҗәләре буенча экономияләнгән акчаларны түбәндәге эшләрне эшләргә яңадан җибәрүгә килешәсезме?:

- КРН-2,1 Б ротацион чапкычы өчен чыгым запас өлешләрен сатып алу.

«ӘЙЕ» «ЮК»

3. Әлеге карарны түбәндәге адреслар буенча урнашкан мәгълүмати стендларда халыкка җиткерергә:

- ТР, Кама Тамагы районы, Иске Барыш авылы, Үзәк урамы, 15 йорт,

шулай ук Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында һәм Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының “Интернет” мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә 3(өч) көн эчендә урнаштырырга кирәк.

4. Әлеге карар халыкка игълан ителгән (басылып чыккан) көненнән үз көченә керә.

5.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

**Татарстан Республикасы Кама**
**Тамагы муниципаль районы**
**Иске Барыш авыл җирлеге**
**Башкарма комитеты җитәкчесе** **И.Р.Җиһаншин**